Казан федераль университеты
Филология һәм мәдәниятара багланышлар  институты
Г.Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе

Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр
фәнни белем бирү үзәге

# ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРНЕҢ БЕЛЕМЕН ТИКШЕРҮ ТЕСТЛАРЫ ӨЧЕН КҮРСӘТМӘ МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ ЭЧТӘЛЕК ЭЛЕМЕНТЛАРЫ КОДИФИКАТОРЫ

## БАШЛАНГЫЧ ДӘРӘҖӘ

КАЗАН
2024

Татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен башлангыч дәрәҗәгә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) – тест үтү эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификатор белем эчтәлегенең һәм аңа куелган таләпләрнең системалы бирелешен хасил итә. Бәяләү материаллары биремнәре өйрәнелә торган эчтәлеккә куелган таләпләргә туры китерелеп төзелде. Кодификатор эчтәлегендә башлангыч дәрәҗәгә туры килгән биремнәргә таләпләр чагылыш таба.

Материаллар бирелеше дүрт бүлек кысасында һәм шулар эчендә бирелгән тел, стилистика, тыңланган һәм укылган текстның эчтәлеген аңлау, телдән һәм язма сөйләм материалын үзләштерү буенча белемнәрне тикшерүне күзаллый.

Кодификаторда эчтәлеге төп тематик блоклар эчендәге киңрәк булган тармаклар, калын курсив хәрефләр белән язылып, кечерәк блокларга бүленде. Кодификаторның әлеге позицияләренең һәрберсе укыту эчтәлегенең берләштерелгән дидактик берәмлекләрен тәшкил итә. Аларга берничә тематик берәмлек керә ала. Тикшерү биреме төзеләчәк эчтәлек элементының коды икенче баганада күрсәтелә.

**1 нче бүлек. Тикшереләчәк эчтәлек элементларының исемлеге**

| **Бүлек коды** | **Тикшерелә торган элемент коды** | **Тикшерелә торган материалның эчтәлеге** |
|---|---|---|
| **1** | | ***Системалы курс. Фонетика. Графика. Орфография. Орфоэпия*** |
| | 1.1 | Татар алфавиты.Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес язу |
| | 1.2 | Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү |
| | 1.3 | Сүзне юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре |
| | 1.4 | Интонация |
| | 1.5 | Сүз басымы |
| | 1.6 | Татар телендә сузык авазлар |
| | 1.7 | Татар телендә тартык авазлар |
| | 1.8 | Сингармонизм законы. Ассимилиция |
| | 1.9 | Татар теленең специфик авазлары |
| | 1.10 | [к], [ғ],[w] авазларын белдергән хәрефләрне дөрес язу |
| | 1.11 | Е, ё, ю, я хәрефләре белдергән авазлар |
| | 1.12 | ь һәм ъ билгеләренең татар сүзләрендә язылышы һәм укылышы |
| **2** | | ***Лексика*** |
| | 2.1 | Сүзнең лексик мәгънәсе |
| | 2.2 | Татар теленең сүзлек составы |

| | | |
|---|---|---|
| | 2.3 | Синонимнар. Антонимнар |
| | 2.4 | Алынма сүзләр |
| | 2.5 | Сүзләрне күчерелмә мәгънәдә куллану |
| | 2.6 | Фразеологик берәмлекләр |
| **3** | | ***Морфемика һәм сүз ясалышы*** |
| | 3.1 | Сүз тамыры |
| | 3.2 | Сүз нигезе |
| | 3.3 | Кушымчалар |
| | 3.4 | Татар телендә кушымчалар ялгану үзенчәлекләре |
| | 3.5 | Тамырдаш сүзләр |
| | 3.6 | Парлы сүзләр |
| | 3.7 | Кушма сүзләр |
| **4** | | ***Морфология*** |
| | 4.1 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем сүз төркеме |
| | 4.2 | Кем?, Нәрсә? сорауларына җавап биргән сүзләр |
| | 4.3 | Исемнең килеш, сан белән төрләнеше |
| | 4.4 | Сыйфат сүз төркеме. Сыйфат дәрәҗәләре |
| | 4.5 | Рәвеш сүз төркеме |
| | 4.6 | Алмашлык сүз төркеме. Зат алмашлыклары |
| | 4.7 | Сорау һәм күрсәтү алмашлыклары |
| | 4.8 | Сан сүз төркеме |
| | 4.9 | Фигыль. Фигыль нигезе |
| | 4.10 | Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше |
| | 4.11 | Фигыль заманнары |
| | 4.12 | Бәйләгеч сүз төркемнәре. Бәйлекләр, теркәгечләр |
| **5** | | ***Синтаксис*** |
| | 5.1 | Җөмлә |
| | 5.2 | Җөмләнең баш кисәкләре |
| | 5.3 | Җөмләнең иярчен кисәкләре |
| | 5.4 | Тиңдәш кисәкләр |
| | 5.5 | Җөмлә ахырында тыныш билгеләре |
| | 5.6 | Җөмләнең аерымланган кисәкләре |
| | 5.7 | Гади һәм кушма җөмлә |
| **6** | | ***Сөйләм үстерү*** |
| | 6.1 | Телдән һәм язма сөйләм |
| | 6.2 | Сүз һәм җөмлә |
| | 6.3 | Текст белән эш |
| | 6.4 | Сүзләрдә авазларның ярашуы |
| | 6.5 | Татар теленең орфоэпик нормалары |
| | 6.6 | Татар сөйләм этикеты |

| | | |
|---|---|---|
| | 6.7 | Диалогик һәм монологик сөйләм |

**2 нче бүлек.**Тикшерелә торган башлангыч дәрәҗәгә куелган таләпләр исемлеге

Таләпләр, системалы-эшчәнлекле юнәлешкә нигезләнеп: *1)тыңлап аңлый, укый һәм яза һәм сөйли алу; 2) гамәли күнекмәләргә ия булу, 3) белү/аңлау* бүлекләренә куела.

**Тыңлап аңлый, укый һәм яза алу** бүлегендә сөйләм эшчәнлегенең әлеге төрләре буенча тест үтүчеләрнең әзерлеге, шулай ук этномәдәни компетенциясе дә тикшерелә.

**Гамәли күнекмәләргә ия булу** бүлегендә татар теле орфоэпиясе, орфографиясе, грамматикасы һәм лексикасын үзләштерүгә, гамәли куллана алуга караган таләпләр куела.

**Белү/аңлау бүлегендә** лексик-грамматик материалны һәм этномәдәни мәгълүматны тел материалы буларак үзләштерүгә куелган таләпләр күрсәтелә.

| Таләп коды | Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге |
|---|---|
| 1 | Авазларны таный һәм аера белү |
| 2 | Татар алфавитын, андагы хәрефләр эзлеклелеген белү |
| 3 | Татар авазларын, аларны белдергән хәрефләрне дөрес әйтә һәм яза белү |
| 4 | Сүзләргә кушымчалар ялгану үзенчәлекләрен аңлау |
| 5 | Сүзләрне иҗекләргә дөрес бүлә белү |
| 6 | Сүз басымын, интонацияне тоеп, дөрес куллана белү |
| 7 | Телнең лексик байлыгын тоемлау һәм белү |
| 8 | Телнең сүз ясалыш үзенчәлекләрен белү |
| 9 | Сүзләрне иҗекләргә бүлеп, үзлегеңнән һәм кычкырып дөрес, сәнгатьле, йөгерек укый белү |
| 10 | Орфоэпик нормаларга нигезләнеп, җөмләләрне дөрес укый һәм сөйли белү |
| 11 | Грамматик билгеләренә бәйле сүзләрне аера белү |
| 12 | Татар телендәге сүз тәртибен аңлап, җөмләләр төзи белү |
| 13 | Җөмлә кисәкләрен, җөмлә төрләрен аера белү |
| 14 | Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен дөрес куя белү |
| 15 | Хәрефләрне, сүзләрне, гади җөмләләрне дөрес яза белү |
| 16 | Җөмлә, текст буенча сорауларга дөрес һәм тулы җавап бирә алу |
| 17 | Кечкенә күләмле текстларны ишетеп, кирәкле мәгълүматны аңлый алу |
| 18 | Өйрәнгән орфографик һәм орфоэпик кагыйдәләрне дөрес кулланып, язмача һәм телдән кечкенә текст төзи белү |

| | |
|---|---|
| 19 | Тыңланган аудиотекстның эчтәлеген аңлый һәм кирәкле мәгълүматны җиткерә алу |
| 20 | Укылган тексттан кирәкле мәгълүматны таба белү |
| 21 | Төрле аралашу ситуацияләренә бәйле текстларны аңлый алу |
| 22 | Төрле аралашу ситуацияләрендә татар сөйләм этикетын дөрес куллана алу |
| 23 | Җөмлә һәм текстны йөгерек итеп, дөрес интонация белән укый белү |
| 24 | Кечкенә тексттагы җөмләләр арасындагы логик эзлеклелекне тоя һәм дөрес куллана белү |
| 25 | Сорау, хикәя, тойгылы җөмләләрнең интонацион һәм мәгънәви үзенчәлекләрен аера белү |
| 26 | Көнкүреш темаларга караган актив лексиканы, гади сөйләмдә еш кулланыла торган грамматик чараларны белү һәм сөйләмдә дөрес куллана алу |